

# Яңа көн

Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем биру мәктәбе

*сентябрь*




*Хөрмәтле укытучылар һәм укучылар! Алда – чираттагы уку елы. Әлеге уку елында без моңа кадәр алган белемнәрне ныгытырбыз, алар янына яңаларын кушарбыз. Җәен ял итеп килгән, бакчаларда эшләп тагын да күбрәк көч туплаган кулларыбыз яңа һөнәрләр үзләштерергә әзер. Башларыбыз саф, күзләребез яңа көнгә елмаеп карый. Димәк, без Белем иленең ишекләрен киң итеп ачып керергә әзер. Бәйрәм белән сезне, дуслар!*



## Бу санда


"Акчарлак" балалар лагеры

Белем бәйрәме

Яңалыклар








Олы бәйрәм бүген бездә,
Ул беренче сентябрь.
Шатлык балкый йөзләрдә,
Бүген син дә, мин дә бер.

Беренче сентябрь – минем
Бәхет – шатлыклы көнем.
Сагынып белем учагын
Мин кабат сиңа килдем.

# "Акчарлак" ял лагеры

Быел җәй районда унтугыз мәктәптә җәйге сәламәтләндерү лагерьлары оештырылды. Аларда барлыгы 600 бала ял итте. Безнең мәктәп базасында урнашкан «Акчарлак» лагеры укучыларның яраткан ял урынына әверелде. Ул быел 40 баланы кабул итте. Шулай ук «Дулкын» хезмәт лагеры уңышлы эшләде, балалар бу лагерьда мәктәп тәҗрибә участогында чыныгу алдылар.





# Яңалыклар

Республика Хөкүмәте тарафыннан «Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр Милли мәгарифне үстерү концепциясе» кабул ителде, аны гамәлгә куюның чаралар исемлеге билгеләнде. 2017 елда Концепцияне гамәлгә куюның «Юл картасы» нигезендә эш программаларын яңарту, барлык юнәлешләр өчен дә яңа буын дәреслекләр чыгару планлаштырыла. Төп игътибар программаларны да, дәреслекләрне дә катлаулы тел материалыннан азат итүгә, телне аралашу чарасы буларак укытуга биреләчәк.

2017 елда һәр муниципаль район һәм мәктәп тәрбия эше белән идарә итүнең бердәм моделе һәм стандартлар буенча эшләячәк. Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү, аларга җәмгыятьтә үз урынын табарга булышу министрлыкның төп эш юнәлешләренең берсе булачак. Республика президенты йөкләмәсе буенча әлеге юнәлеш, милли мәгариф үсеше мәсьәләләре белән беррәттән, Мөслим районында узачак август педагогик киңәшмәсенең төп темасы буларак билгеләнде

16 августтан фән укытучыларының август киңәшмәләре башланып китте. Киңәшмәләрдә районыбыз мәктәпләре мөгаллимнәре укыту системасындагы яңалыкларны өйрәнделәр, яңа ФГОСка күчү шартларында инновацияләр турында фикер алыштылар, алдагы эшчәнлекне оештыру планнарын расладылар

28 август көнне Балык бистәсе муниципаль районы мэгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе булып үтте. Бу бәйрәмгә безнең мәктәп укытучылары бик яхшы әзерләнделәр, методик эшләнмәләр күргәзмәсе һәм экология елына багышланган “Мәктәп бакчасында” исемле композиция  әзерләделәр.





